СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.08.2022 Баулы шәһәре 126

Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы карарына (2020 елның 29 маендагы 262, 14.12.2021 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бюджет процессында гражданнарның катнашуы»;

18 статьяның 15 абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бурыч тотрыклылыгы югары яисә уртача дәрәҗә булган заемщиклар төркеменә кертелгән район бюджетының хисап финанс елында үтәлеше барышында бюджет ассигнованиеләрен тулысынча файдаланмауга бәйле барлыкка килгән калдыклар арасындагы аермадан артмаган күләмдә һәм әлеге статьяның икенче абзацында каралган бюджет ассигнованиеләрен арттыру суммасында бюджет

хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган район Советының муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә кулланыла.»;

19 статьяның 23 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район тарафыннан бирелгән һәм максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында муниципаль гарантияләрдән чит ил валютасында бирелә торган йөкләмәләр күләме.»;

24 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле бюджетка акчалар җәлеп итү күләмнәре чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы заем алу программалары белән билгеләнә, һәм тиешле финанс елында акчалар җәлеп итүнең гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелә торган акчаларның гомуми суммасыннан һәм, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 һәм 104 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып, җирле бюджет турындагы карар белән тиешле финанс елына расланган инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган өлеше күләменнән тыш, Районның бурыч йөкләмәләрен каплау күләмнәреннән артмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
урынбасары, район Советы
Рәисе урынбасары Р.Г. Хәмидуллин